ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СИЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д. 1, с. Смак-Корса,
Арский муниципальный район, 422025

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СЕЖЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Мәктәп урамы, 1 йорт, Курса Почмак авылы,
Арча муниципаль районы, 422025

Тел. (84366)53-2-36, факс (84366)53-2-36. E-mail: Smk.Ars@tatar.ru

# КАРАР

**24 декабрь 2021 ел** **№ 42**

**«Сеҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Сеҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, 08.11.2021 №2,№3,09.11.2021 №4,10.11.2021№5,№6,11.11.2021 №7,15.11.2021№8,№9,16.11.2021№10,№11,17.11.2021№12,18.11.2021№13,19.11.2021 №14,22.11.2021 №15җыеннарда кабул ителгән «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Сеҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 28 октябрендәге 41 номерлы Сеҗе авыл җирлеге Советы карары нигезендә Сеҗе авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Сеҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: ТР, Арча районы, Курса Почмак авылы,Мәктәп урамы,1 нче йорт,Сикертән авылы,Үзәк урам,14 нче йорт,Сеҗе авылы,Мәктәп урамы,25 нче йорт.
3. «Сеҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында» Сеҗе авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 18 декабрендәге 41номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Сеҗе авыл җирлеге башлыгы Хамидуллин Р.В.

Сеҗе авыл җирлеге
Башкарма комитетының
24 декабрь2021 ел, №42
карарына 1 нче кушымта

**«Сеҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге тәртип «Сеҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчасы 2022 елның 22 февраленә кадәр «Сеҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән, җыеннарда катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдергән мөнәсәбәтләре нинди булуга карамастан, 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан түләнә.

3. Аерым категория гражданнар:

а) көндезге бүлектә укучы студентлар,

б)1 төркем инвалидлар,

в) 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнар өчен

түләү күләме җирле җыеннарда билгеләнгән суммадан 50 (илле) процент тәшкил итә.

4. Нигезле сәбәпләр:

а) гаилә әгъзасының үлеме (ата-ана, хатыны/ире, балалары),

б) янгын яки башка табигый бәла-казалар нәтиҗәсендә зыян күрү булганда булганда

гражданнарга гариза нигезендә өч айдан артмаган вакытка түләү кертүне кичектереп тору каралган булырга мөмкин.

5. Бер тапкыр түләү турында гражданнарга хәбәр итү хәбәрнамә бланкын Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында урнаштыру, шулай ук кул куйдырып шәхсән бирү яисә почта аша җибәрү юлы белән җиткерелә.

Хәбәрдә (хәбәрнамәдә) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерү өчен түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан җыелган акчалар «Сеҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең шәхси счетына керә.

7.Түләүләр физик затлар поручениесе буенча почта аша исәп-хисап ясау хокукына ия булган оешма аша күчерелә.

8. Түләүне дәлилли торган документ булып касса керем ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар тора.

9. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Сеже авыл җирлеге
Башкарма комитетының
24 декабрь ел, №42
карарына 2 нче кушымта

# ХӘБӘР (ХӘБӘРНАМӘ) № ______________

«Сеже авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча бер мәртәбә түләү турында

Түләүченең ф. и. а.и.______________________________________________
Адресы:__________________________________________
______________________________________________________нигезендә
Сезгә 2022 елның 22 февраленә кадәр төзекләндерү чараларын гамәлгә ашыруга ________________ сум күләмендә түбәндәге реквизитлар буенча:
РОССИЯ БАНКЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МБ БҮЛЕГЕ// ТАТАРСТАН БУЕНЧА УФК Казан ш.
Алучы банкы БИК ___019205400
Алучы сч. № 03100643000000011100
Алучы сч. № 401028104453700079 банк хисабы
ИНН _1609009548
КПП _____160901001
КБК _89511714030 13 0000 150
ОКТМО _92612151
Түләү билгеләнеше- гражданнарның шәһәр җирлекләре бюджетларына күчерелә торган үзара салым акчалары

бер тапкыр түләнә торган түләү кертергә кирәк.

Җитәкче __________________ ______________________________________
(имза) (имзаның аңлатмасы)
М. у.

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү сызыгы- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

Түләүченең ф. и. а.и.__________________________________________
Адресы: ______________________________________________________
________________сум күләмендә бер тапкыр түләнә торган үзара салымны «Сеже авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетына кертү турында ___ номерлы хәбәрне (хәбәрнамә) алдым:

«___» __________ 20__ ел ____________________________________
(имза/түләүченең ф.и.а.и.)

*Искәрмә: хәбәрнамә түләүчегә шәхсән бирелгән очракта, өзек корешок тотырыла һәм _______________ җирлеге башкарма комитетында кала.*